**Гайнулла бабай Хисматуллин турында истәлекләр (1855-1935)**

Гайнулла бабай- әнием Галимәнең әтисе Фассах бабайның әтисе.

Сабыр холыклы, төпле фикерле Гайнулла бабай өченче хатыны (алдагы ике хатыны чирләп үлгәннәр) Шамсенаһар әби белән 7 малай (Габдерахман, Абзалетдин, Камалетдин, Имаметдин, Фассахетдин, Салахетдин, Хаҗинур) һәм 3 кыз (Миннекамал, Шамседоха, Зөләйха) үстергәннәр. Бабай бөтен өйләнгән малайларын үзенең милеге тирәсендә йорт салдырып башка чыгарган. Бугенге "Олы чишмәгә" төшә торган урамның (ул урамны без кечкенә чагында "Әсмә тавы" дип йөртәләр иде) уң ягында берсенә берсе терәлеп "Күчәгәрләр"ләрнең 7 милекләре торган. Шул милектә Маһира әбинең, Мәүлидә ападан кала, барлык балалары туган. Минем әнием Галимә дә шунда туган. Ул елларда янгын чыгып милекләр яну еш күренеш булган. Гайнулла бабай нәселен дә бу афәт читләтеп үтмәгән. Янган милектән күчеп торып, аның малайлары яңа өй җиткереп тагын үз милекләренә кайта торган булганнар. Шуңа күрә аларга "Күчәгәрләр", күченеп йөрүчеләр дип кушамат биргәннәр.

Гайнулла бабайның уртанчы улы Фассахетдин үсеп җиткәч, түбән очта торучы Ислам кызы Маһира белән яратышып йөри башлый. Ләкин бу хәл Гайнулла бабайга бик ошап бетми, ахрысы- Маһира Фассахетдиннән 2 яшькә олырак була. Шулвакыт яшьләрне аерырга җае да чыгып куя. Кызы Маһираның авылның булдыклы егете Фассахетдин белән дус булуына шатланган Бибигазизә әби үзенең күршеләренә мактана: "Өйләнүләре белән Гайнулланың малае Фассахетдинне үзебезнең йортка алып кайтабыз- безнең малайларыбыз юк, ә милеккә дә яшь хуҗа кирәк бит". Ул вакытта хатыны йортына килү егет кеше өчен дә, нәсел өчен дә зур кимсетелү булган. Маһира әбинең әтисе Ислам бабай хатынының сүзләрен ишеткәч болай ди: "Авызыңны ачканчы бергә утырып

киңәшергә кирәк иде, карчык. Егете бик уңган, бик булдыклы- аны алай кимсетергә ярамый. Синең сүзләреңнән соң инде ул безнең якка борылып та карамас”. Билгеле инде, Бибигазизә әбинең сүзләрен тиз генә Гайнулла бабайга да җиткерәләр. Аңа шул җитә кала- Гайнулла бабай улы Фассахетдинне тиз генә димләп авылның матур кызы Бәнәт әбигә (түбән очта олы урамда торган Шарафиев Габделхай абыйның әнисе) өйләндерә. Әти сүзенә каршы килә алмыйлар ул вакытта! Фассах бабай шуннан соң “тыныч бунт”ка күчә: яшь килен торган әтисе өендә бер тапкыр да кунмый- гел бертуган абыйларына кереп куна. Бу хәлне күреп, киленнең әтисе аны кире өйләренә алып кайтып китә. Фассах бабай әтисенә әйтә: “Теләсә кемгә өйләнерсәгез дә, мин Маһирадан башка беркем белән дә тормыйм!” Гайнулла бабай шуннан соң 2 ел үткәч улы Фассахетдингә Маһира әбине сорарга Ислам бабайга яучылар җибәрә.

Ул вакыттагы гадәт буенча, әти-әни йортында төпчек улы гаиләсе кала торган булган. Ләкин Гайнулла бабай бу гадәтне үзенчә борган. Оста, җитез, уңган Маһира киленен тормышта күреп, ул болай дигән: “Фассахетдин, төп йортта син каласың Маһира килен белән”. Ә бит Фассах бабай төпчек булмаган, аның әле Сәләхетдин һәм Хаҗинур исемле энеләре булган! Маһира әбине каенатасы гына түгел, иренең энеләре дә үз күргәннәр. Яңа өйләнешеп башка чыккач, яшь гаиләдә җитешмәгән әйберләр күп була бит инде. Шул чагында икмәк, ит сорап алар турыдан Маһира әбигә килгәннәр- әби барысына да кулдан килгәнчә булышкан. Аның изгелекләрен алар соңыннан гел искә ала торган булганнар.

Әби яңа гаиләдә үзен дә куя белгән. Аның үзенең мәзәк итеп болай дип безгә сөйләгәне бар иде: “Мин мич янында олы табакка коймак пешереп йөрим- гаилә зур бит, күршедән Фассахның абый-энеләре дә еш кергәлиләр коймак исенә. Гайнулла әтинең кәефе юк бугай: аңа мин эшләгән я бер нәрсә, я икенчесе ошамый, кисәтү

ясап кына тора. Мин бер сүз дә әйтмим- ул вакытта яшь киленнәр “тел яшерергә”, ягъни каената белән авыз ачып сөйләшмәскә тиеш. Коймакны пешереп бетердем дә, табакны үземнең алга куйдым. Шуннан бер сүз дә әйтмичә бөтен коймакны берүзем ашап бетердем. Әти аллы- артлы йөрде өйдә, ләкин бер сүз дә әйтмәде миңа. Ашап бетергәч, тордым да ишек алдына эшләргә чыгып киттем һәм караңгы төшкәнче өйгә кермәдем. Шул хәлдән соң Гайнулла әти үзе үк миңа сүз әйттерми иде: “Ул сулагайның (Маһира әби сулагай –“левша” иде) ачуын китерә күрмәгез, тагын барабызны да ач калдырыр”.

Тагын бер тапкыр янгын чыгып, “Олы чишмә” урамында 20 гасырның 30 еллар уртасында 17 хуҗалык янган. Шул чагында Ислам бабай Фассах кияүен кызы белән үз милегенә торырга чакырган. Ләкин иң беренче булып моңа Маһира әби каршы торган: “Фассахны кимсетеп, мин әти милегенә кайтмыйм”. Шул чагында Гайнулла бабай Фассах улы гаиләсенә Зәңгәр өй (хәзерге Хабибуллин Шайхеләхмәт абый милеге) алып бирә. Ләкин анда алар гел саташып, тынгылык таба алмаганнар. Инде Гайнулла бабай килгән аларга киңәш белән: “Ислам кода белән сөйләштек. Яше инде күп, сәламәтлеге дә бик ныклы түгел. Төп милектә калучысы юк, алар хәзер хатыны белән икәү генә торалар. Фассах улым, Маһира килен, ташламагыз Ислам коданы. Күчегез аның милегенә”. Шулай итеп, бабай белән әби кече урамдагы (хәзерге Молодежный урамы) түбән очтагы Ислам бабай йортына күченәләр 1935 еллар тирәсендә. (Бер елдан соң, 1936 елда, алар хөрмәтләп Ислам бабайны соңгы юлга озаталар... 1940 елда Ислам бабайның хатыны Бибигазизә әби дә дөнья куя).

Ислам бабай бик шатлана: беренчедән милекне киявенең ныклы кулларына калдыра. Икенчедән, оныгы Мулланур үсеп килә. Бердәнбер оныгы Мулланур турында  Ислам бабай болай дигән: “Бу малайны карап кына үстерергә кирәк инде- милек тота торган

малай булыр микән инде ул”. Чөнки Мулланур абыйга кадәр Маһира әбинең 3 улы Фәрәхетдин, Фәтхетдин, Мөхәмәтдин яшьли үләләр. Мулланур абыйның да исән калуына шик тота Ислам бабай. Ләкин бу юлы ул нык ялгыша: Мулланур абый, сугышка китеп 1942 елда Смоленск тирәсендә югалган Фассах әтисен алмаштырып, 11 яшьтән колхозда ат җигеп әнисенең һәм 3 сеңлесенең ныклы таянычы була. Ул шундый эшли, хәттә сугыш азагында 15 яшендә тыл хезмәтчәннәре өчен чыгарылган “За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945г.г.” медале белән бүләкләнә. Соңыннан колхозда, Ислам бабай кебек, балта осталары бригадиры була. Аннан соң ул озак еллар “Кама” колхозында иң авыр эшләрнең берсендә- кырчылык бригадасында бригадир булып эшли. Аның фидакарь хезмәтләре орден-медальләр белән билгеләп үтелә. Үзе Сания апага өйләнгәч, Ислам бабасы милегенә менә дигән биш почмаклы йорт салып куя.

...Кире “Олы чишмә” урамына әйләнеп кайтыйк. Гайнулла бабайның бик җитез чабыш атлары булган. “Ат- ир күрке” дигән бит халык. Шуларның берсе, иң җитезе, беркайчан да җайдак белән чапмаган- ул аларны борылып тешләп, җиргә алып ташлый торган булган. Сабантуйда җайдаксыз гел беренче булып килүче атны күргән авылдашлар: “Гайнулла аты килә”- ди торган булганнар. Бу “ат җене” Гайнулла бабайның оныкчыкларына да күчкән, ахырысы: Тазиев Рәфиснур белән Мансур, Рәфиснурның улы Марат инде 1980 еллардан бирле авылда гына түгел, хәттә тирә-юньдә, Казанда бер сабантуйдан да калмыйча, ат чабышларында катнашып, призлы урыннар алып баралар. Тарих шулай дәвам итә...

*Кәлимуллин Рәшит, 2018 ел, январь*